# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

## КАРАР
IV чакырылыш IX утырышы

15 февраль 2022 ел № 14 Урыссу ш.т.п.

2021 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
социаль-икътисадый үсеше йомгаклары
һәм 2022 елга бурычлар хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2021 елга социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2022 елга бурычлар турында» докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2022 елга бурычлар турында» хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына 2022 елның 15 мартына кадәр вакытка:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы хисабында, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы икътисад министры, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутатлары чыгышларында әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Ютазы район Советына карауга тәкъдим итәргә;

- Максаты икътисадны тотрыклы, динамикалы үстерү һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы мохит булдыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын яхшыртырга тиеш булган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын социаль-икътисадый үстерү планнарын уңышлы үтәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрен һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- салым салу базасын булдыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлеге бюджетларына җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча өстәмә финанс чараларын җәлеп итү буенча эшчәнлекне активлаштырырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы һәм Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрендә гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүләрне тигез алу мөмкинлеген тәэмин итү чараларын күрергә;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрен һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районын төзекләндерү, яшелләндерү һәм торак пунктларны санитар чистарту, экологик иминлек тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин